**КАРАР**

**Татарстан Республикасы Азнакай район Советы**

№198-30 22 август 2018 ел

«Азнакай муниципаль районының
“Мактаулы гражданины "
исемен бирү турында»

Азнакай район Советының 2011 елның 20 сентябрендәге 76-12 номерлы карары белән расланган «Азнакай муниципаль районының Мактаулы гражданины» исеме турындагы положениясе нигезендә Азнакай районы һәм Азнакай шәһәре үсешенә зур өлеш керткән гражданнарның абруен ныгыту, аларның халыкара аренада, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасында дәрәҗәсен күтәрү максатынан

Татарстан Республикасы Азнакай район Советы **карар чыгарды:**

1. Азнакай муниципаль районының” Мактаулы гражданины " исемен бирергә:

- Вәлиев Альберт Мөхәммәтҗан улы, 1967 – 1999 елларда Азнакай «Сельхозтехника» җитештерү предприятиесе җитәкчесе (үлгәннән соң).

- Осипов Николай Егор улы, 1971 елның июненнән 2008 елның декабренә кадәр Азнакай бораулау эшләре предприятиесенең нефть һәм газ скважиналарын эксплуатация һәм разведка бораулаучысы , нефть һәм газ сәнәгате ветераны.

2.1. Мактаулы граждан исеменә лаек булган затларга «Азнакай муниципаль районының Мактаулы гражданины " таныклыгын тапшырырга»;

2.2. Россия Федерациясе Салым кодексының 207 статьясы нигезендә физик затлар керемено салым тотып, 20 000,00 сум (егерме мең сум 00 тиен) күләмендә бер тапкыр бирелә торган түләү тапшырырга.

2.3.Мактаулы гражданнарның исемнәрен Азнакай муниципаль районының Мактаулы гражданнары китабына кертергә.

3. Әлеге карарны Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча бастырырга: http://aznakayevo.tatarstan.ru.

Рәис М.З.Шәйдуллин